*Консультация для родителей татарских групп:*

***“Балаларны ФГОС буенча татар теленә өйрәтүдә ата-аналарның роле”***

Татар теле… Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күпгасырлык тарихы булган, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, җитлеккән, камилләшкән горур татар теле!

Татар теле… Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күпгасырлык тарихы булган, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, җитлеккән, камилләшкән горур татар теле! Киләчәктә балама күбрәк рус теле кирәк булачак, туган тел качмас дигән ялгыш фикердә торучы ата-аналар да күп әле бүгенге көндә. Ата-аналарның шушы ялгыш карашларын төзәтү, татар теле – халкыбызның буыннан-буынга күчеп килүче рухи, мәдәни байлыгын саклаучы, буыннар чылбырын тоташтыручы, көнкүрештә барлык өлкәләрдә кулланыла торган аралашу чарасы икәнлеген аңлату уртак бурычыбыз.

Балага туган телдә мәхәббәт тәрбияләүдә ата-ананың, тәрбияченең роле зур.

Шулай да бала телне белсен өчен иң элек гаилә җаваплы. Аннан соң балалар бакчасы, мәктәп.

Кеше никадәр тел белә – рухи яктан шулкадәр баерак дигән гыйбарә бар. Чынлап та, ике тел белгән баланың фикерләү дәрәҗәсе бер тел белгән баланыкына караганда күпкә көчлерәк. Күп телләр белгән кеше хәтерле, эрудицияле була.

Бүгенге көндә балалар бакчаларында Федераль дәүләт мәгариф стандартын (ФГОС) тормышка ашыру юнәлешендә эш алып барыла. Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартында мәктәпкәчә яшьтәге баланың физик һәм психик сыйфатларын төрле яклап үстерерү, аларның сәламәтлеген ныгыту, күңелләренә әхлак кагыйдәләрен сеңдерү , баланы хәзерге җәмгыятьтә яшәргә әзерләү зарурлыгы күрсәтелә. Балаланың кызыксынуларын арттыру,танып белү омтылышын ,күзаллавын ,иҗат активлыгын үстерү,анда мөстәкыйльлек, макатчанлык,үз эш-гамәлләре белән идарә итә белү күнекмәләре булдыру игътибар үзәгенә куела.

Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты билгеләнгәнчә, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеге 5 юнәлештә оештырыла һәм алып барыла: социаль аралашу үсеше, танып-белү үсеше, сөйләм үсеше, нәфис-нәфасәти үсеш, физик үсеш.

Бүген мәктәпкәчә белем бирү оешмаларыалдында торган төп бурыч- мәктәпкәчә яшьтәге балаларның җәмгыятьнең тулы хокуклы әгъзалары булып җитешүе,рухи-әхлакый үсеше ,иҗади сәләтләренең камилләшүе , шәхси кызыксынуларының, омтылышларының тормышка ашуы өчен мөмкинлек тудыра торган шартлар,ягъни баланың һәрьяклы үсешен тәэмин итә торган белем бирү тирәлеге булдыру.

Баланың аңы өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән уртак эшчәнлектә генә түгел, ә мөстәкыйль эшчәнлектә дә үсә. Шуңа күрә тәрбиячегә баланың үзлегеннән үсеш процессына, мөстәкыйль иҗади башлангычларына этәргеч көч булып торган предметлы-үстерелешле мөхит оештыру мөһим. Аның төп өлешен балаларны ана һәм рус телләренә өйрәтү буенча укыту-методик комплекты(УМК) алып тора.

УМКга методик әсбаплар, программалар, хрестоматияләр, эш дәфтәрләре,тематик картинкалар,күрсәтмә һәм тарату материаллары, мульти-медиа чаралары кирә.Бу комплектларга балаларны татар һәм рус телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү ,балаларны кызыксындыра алырлык аралашу даирәсе булдыру,сюжетлы уеннар оештыру,гомумән, балаларның актив сөйләмен үстерү максаты куелган. Шөгыльләрдә УМК киң кулланыла, ягъни, без ана, рус телләрендә мультфильмнар карыйбыз, хикәяләр, әкиятләр укыйбыз һәм балалар белән бергә эчтәлеген сөйләп карыйбыз,сюжетлы-рольле, хәрәкәтле һәм түгәрәк уеннар уйныйбыз. Җырлар өйрәнәбез , шигырьләр ятлыйбыз. Картиналар буенча хикәяләр төзергә өйрәнәбез.Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартында уен аша тәрбия һәм белем бирүгә нык игътибар ителә.

Тәрбиянең төп асылы - балалар бакчасы белән гаиләнең бердәмлегендә. Баланың һәрьяклап камил үсешен тәэмин итү өчен мәктәпкәчә белем учреждениеләре алдында гаилә белән үзара хезмәттәшлек итү бурычы тора. Бергә хезмәттәшлек итеп, ярдәмләшеп, балага бердәм таләпләр куеп эшләгәндә генә уңай нәтиҗәләргә ирешергә, баланың һәрьяклап камил үсешен тәэмин итәргә мөмкин. Бакчабызда ата-аналар һәм балалар белән “Минем иң яраткан мультфильмым”, “Габулла Тукай әкиятләре”нә иллюстрацияләр, “Мин - юлда хәвефсезлек яклы”, “Шырпы белән сак бул!” кебек рәсем конкурслары, кул эшләнмәләреннән күргәзмәләр оештырыла, төрле бәйрәм иртәләре, эшлекле уеннар гаилә белән балалар бакчасын берләштерүче үтемле, нәтиҗәле чаралар булып тора.

Уен бала тормышында әйдәүче эшчәнлек булып тора. Ул балалар бәхете өчен, аларның сәламәтлеге һәм дөрес үсеше өчен кирәк. Уен балаларны сөендерә,аларның күңелен күтәрә. Уйнаганда алар күп хәрәкәтләнәләр: йөгерәләр, сикерәләр, корылмалар төзиләр. Шуның нәтиҗәсендә балалар көчле, батыр, җитез сау – сәламәт булып үсәләр. Уен уйлау эшчәнлеген, фантазияне үстерә . Бергә уйнап балалар дус – тау яшәргә,бер – берсенә юл куярга, бер – берсе турында кайгыртырга өйрәнәләр.

Киңәшләр: Ял вакытларыгызда балалар белән урманга, елгага “сәяхәткә” барыгыз, кышын ап-ак кар өстендә чаңгы юллары сызыгыз, кар йомарлап атышыгыз. Балалар сихри дөньяда булып, хис итәргә, тоемларга, хыялланырга өйрәнәләр, табигать матурлыгын тояргa өйрәнәләр. Алар физик яктан да, рухи яктан да ял итәләр. Шулай ук сулыш күнегүләре дә ясала, йөз, артикуляция, бармак гимнастикасы да ясала, авазлар да ныгытыла, сүзлек тә байый, активлаша. Балачак чыннан да бәхетле, кайгысыз булсын дисәк, балаларга рәхәтләнеп яшәргә шартлар булсын.Әйдәгез үзебезнең балалар белән ешрак уйныйк.

